КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 1 декабрь г.Казань № 1025

2025 елда устав эшчәнлеген гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен «Татарстан Республикасының Инвестиция-венчур фонды» коммерциягә карамаган оешмасына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2025 елда устав эшчәнлеген гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен «Татарстан Республикасының Инвестиция-венчур фонды» коммерциягә карамаган оешмасына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен расларга.
2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 1 декабрь, 1025 нче
карары белән расланды

2025 елда устав эшчәнлеген гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен «Татарстан Республикасының Инвестиция-венчур фонды» коммерциягә карамаган оешмасына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибе

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга, шулай ук товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче физик затларга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан, җирле бюджетлардан субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне һәм әлеге субсидияләрне, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантларны алучыларны сайлап алуны үткәрүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләрне раслау турында» 2023 елның 25 октябрендәге 1782 номерлы карары, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнде һәм 2025 елда устав эшчәнлеген гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен «Татарстан Республикасының Инвестиция-венчур фонды» коммерциягә карамаган оешмасына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия (алга таба – коммерциягә карамаган оешма, субсидия) бирү тәртибе максатын, шартларын һәм механизмын билгели.

1.2. Субсидия бирүнең максаты – коммерциягә карамаган оешманың устав эшчәнлеген гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны түбәндәге өлештә финанс белән тәэмин итү:

фән казанышларына нигезләнгән җитештерүләрне үстерүгә һәм яңа прогрессив технологияләрне кулланышка кертүгә юнәлдерелгән чаралар үткәрү;

инновация эшчәнлегенә ярдәм күрсәтү, продукцияләрнең һәм технологияләрнең яңа төрләрен җитештерүне әзерләү һәм үзләштерү өчен юридик затларга максатчан заемнар бирү;

Татарстан Республикасының инновация һәм инвестиция потенциалын арттыру максаты белән күргәзмә эшчәнлеген гамәлгә ашыру;

коммерциягә карамаган оешманың һәм «Россия технологик үсеш фонды» федераль дәүләт автоном учреждениесенең уртак программалары кысаларында проектларны гамәлгә ашыру өчен юридик затларга максатчан заемнар бирү.

1.3. Субсидия 2025 елга Татарстан Республикасы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм субсидия бирү өчен бюджет акчасын алучы буларак Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына (алга таба – Министрлык) билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

1.4. Субсидия алучыга субсидия бирүне гамәлгә ашыручы, Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче булып Министрлык тора.

1.5. Субсидия турында мәгълүмат «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасы бердәм порталының «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.

## II. Коммерциягә карамаган оешмага карата таләпләр

2.1. Әлеге Тәртипнең кушымтасында бирелгән форма буенча субсидия бирүгә гариза (алга таба – заявка) бирелә торган айның 1 нче көненә карата коммерциягә карамаган оешма түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормаска тиеш. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;

экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы барлыгы турында белешмәләр булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

БМО уставының VII бүлегендә каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру кысаларында БМО Куркынычсызлык Советы яки БМО Куркынычсызлык Советы карарлары белән махсус оештырылган органнар тарафыннан төзелә торган террорчылык оешмалары һәм террорчылар белән яки массакүләм юк итү коралын тарату белән бәйле оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

әлеге Тәртипнең 1.2 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алмый;

«Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлеген тикшереп тору турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты булып тормый;

бердәм салым исәбендә Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү буенча бурычы булмый яисә Россия Федерациясе Салым кодексының 47 статьясындагы 3 пунктында билгеләнгән күләмнән артмый;

башка субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен Татарстан Республикасы

бюджетына кире кайтару буенча срогы чыккан бурычы, шулай ук Татарстан Республикасы алдында акчалата йөкләмәләр буенча башка срогы чыккан (җайга салынмаган) бурычы булмый (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән очраклардан тыш);

үзгәртеп оештыру (коммерциягә карамаган оешмага башка юридик затны кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында тормый, коммерциягә карамаган оешмага карата банкротлык процедурасы билгеләнмәгән, эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән каралган тәртиптә туктатылмаган;

дисквалификацияләнгән затлар реестрында дисквалификацияләнгән җитәкче, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, бердәм башкарма орган функцияләрен башкаручы зат яки коммерциягә карамаган оешманың баш бухгалтеры (булганда) турында мәгълүматлар булмау.

## III. Субсидия алу өчен документлар

3.1. Министрлык тарафыннан бердәм порталда субсидия турында мәгълүмат урнаштырылган көннән соң килә торган 10 эш көне эчендә субсидия алу өчен коммерциягә карамаган оешма Министрлыкка, түбәндәге документларны теркәп, заявка бирә:

заявка бирелә торган айның 1 нче көненә карата Татарстан Республикасы бюджетына башка субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен, шулай ук Татарстан Республикасы алдындагы акчалата йөкләмәләр буенча срогында түләнәмәгән (җайга салынмаган) башка бурычларны кире кайтару буенча срогында түләнәмәгән бурычы булмау турында коммерциягә карамаган оешманың җитәкчесе тарафыннан имза куелган белешмә кәгазе;

заявка бирелә торган айның 1 нче көненә карата коммерциягә карамаган оешманың әлеге Тәртипнең 1.2 пунктында күрсәтелгән максат өчен Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджеты акчасын алучы булмавы турында коммерциягә карамаган оешманың җитәкчесе тарафыннан имза куелган белешмә кәгазе;

заявка бирелә торган айның 1 нче көненә карата үзгәртеп оештыру (коммерциягә карамаган оешмага башка юридик затны кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында булмавы, аңа карата банкротлык процессы билгеләнмәве, коммерциягә карамаган оешма эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән каралган тәртиптә туктатылмавы турында коммерциягә карамаган оешманың җитәкчесе тарафыннан кул куелган белешмә кәгазе;

заявка бирелә торган айның 1 нче көненә карата коммерциягә карамаган оешма җитәкчесе, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, аерым шәхес башкарма органы функциясен үтәүче зат яисә коммерциягә карамаган оешманың баш бухгалтеры (булганда) дисквалификацияләнгән затлар реестрында булмавы турында коммерциягә карамаган оешманың җитәкчесе тарафыннан имза куелган белешмә кәгазе;

заявка бирелә торган айның 1 нче көненә карата коммерциягә карамаган оешманың чит ил юридик заты, шул исәптән офшор компаниясе, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры

булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булмавы турында коммерциягә карамаган оешманың җитәкчесе тарафыннан имза куелган белешмә кәгазе;

заявка бирелә торган айның 1 нче көненә карата коммерциягә карамаган оешма экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы барлыгы турында белешмәләр булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормавы турында коммерциягә карамаган оешманың җитәкчесе тарафыннан имза куелган белешмә кәгазе;

заявка бирелә торган айның 1 нче көненә карата БМО Уставының VII бүлегендә, БМО Куркынычсызлык Советы яки БМО Куркынычсызлык Советының карарлары белән махсус төзелгән органнар тарафыннан каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру кысаларында төзелә торган террорчылык оешмалары һәм террорчылар белән яки массакүләм юк итү коралын тарату белән бәйле оешмалар һәм физик затлар исемлегендә коммерциягә карамаган оешманың булмавы турында коммерциягә карамаган оешманың җитәкчесе тарафыннан имза куелган белешмә кәгазе;

заявка бирелә торган айның 1 нче көненә карата коммерциягә карамаган оешманың «Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлегенә контроль турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты булмавы турында коммерциягә карамаган оешманың җитәкчесе тарафыннан имза куелган белешмә кәгазе;

коммерциягә карамаган оешма уставы күчермәсе;

коммерциягә карамаган оешма җитәкчесе вәкаләтләрен раслый торган документлар күчермәләре;

финанс-икътисадый нигезләвен теркәп, чыгымнар күләмен нигезли торган мәгълүматны, шулай ук аны алу чыганагын (товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итүчеләрнең счетларын, житештерүче оешмаларның бәяләре турында, дәүләт статистикасы органнарында, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларында һәм махсус әдәбиятта булган (житештерүчеләрнең һәм тәэмин итүчеләрнең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларын кертеп) бәяләр дәрәҗәсе турында мәгълүматны күрсәтеп, әлеге Тәртипнең 5.2 пунктында күрсәтелгән юнәлешләр буенча чыгымнар сметасы;

2025 елга коммерциягә карамаган оешманың расланган финанс планы;

коммерциягә карамаган оешманың Күзәтчелек советы беркетмәсеннән 2025 елга коммерциягә карамаган оешманың финанс планына әлеге Тәртипнең 5.2 пунктында күрсәтелгән чыгымнар юнәлешләре буенча финанслау күләмнәрен үз эченә алган (яисә күздә тоткан) үзгәрешләрне кертү буенча өземтә;

2026 елга коммерциягә карамаган оешманың расланган финанс планы (яки аның проекты).

3.2. Коммерциягә карамаган оешма Министрлыкка түбәндәгеләрне өстәмә рәвештә тапшырырга хокуклы:

Федераль салым хезмәтенең «Салым түләүченең (җыем түләүче, иминият кертемнәрен түләүче, салым агентының) салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча бурычларын үтәве турындагы белешмә

кәгазе формасын һәм аны электрон формада тапшыру форматын раслау хакында» 2022 елның 23 ноябрендәге ЕД-7-8/1123 номерлы боерыгы белән расланган форма буенча заявка бирелә торган айның 1есеннән дә иртәрәк булмаган вакытта салым органы тарафыннан салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча бурычларны үтәү турында бирелгән белешмә кәгазе;

заявка бирү датасына кадәр өч эш көненнән артмаган датага карата Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан Федераль салым хезмәтенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырылган «ЮЗБДР/ИЭБДРннан белешмәләр бирү» сервисын файдаланып формалаштырылган өземтә.

Коммерциягә карамаган оешма тарафыннан әлеге пунктта күрсәтелгән документлар тапшырылмаган очракта, Министрлык әлеге документларны яки мондый документлардагы белешмәләрне ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә ала.

3.3. Тапшырыла торган белешмәләр дөрес булмаган өчен, шулай ук ялган документлар өчен коммерциягә карамаган оешма Россия Федерациясе законнары нигезендә җавап бирә.

Тапшырыла торган барлык документларда чистартулар һәм төзәтүләр (заявканың арткы ягында, гомуми бит саннарын күрсәтеп, мөһер сугылган һәм вәкаләтле затның имзасы һәм коммерциягә карамаган оешманың мөһере белән расланган төзәтүләрдән тыш) булмаска тиеш.

3.4. Коммерциягә карамаган оешма заявканы кире алырга һәм заявка бирү өчен билгеләнгән срок эчендә кабат заявка бирергә хокуклы.

## IV. Заявкаларны кабул итү һәм карап тикшерү тәртибе

4.1. Министрлык заявканы алганда:

Татарстан Республикасының ведомствоара электрон документлар әйләнеше системасы аша заявканы кергән көнендә терки;

заявка теркәлгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә коммерциягә карамаган оешманың һәм тапшырылган документларның әлеге Тәртипнең 2.1 һәм 3.1 пунктларында билгеләнгән таләпләргә һәм шартларга туры килүен тикшерә.

4.2. Министрлык, әлеге Тәртипнең 4.1 пунктындагы өченче абзацы нигезендә үткәрелгән тикшерү тәмамланган көннән алып өч эш көненнән дә соңга калмыйча, субсидия бирү турында яки субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

4.3. Субсидия бирүдән баш тарту өчен нигезләр:

коммерциягә карамаган оешма әлеге Тәртипнең 2.1 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәү;

әлеге Тәртипнең 3.1 пунктында күрсәтелгән документлар тапшырылмау (тулы күләмдә тапшырылмау);

коммерциягә карамаган оешма тарафыннан тапшырылган документлар әлеге Тәртипнең 3.3 пунктындагы икенче абзацында билгеләнгән таләпләргә туры килмәү;

коммерциягә карамаган оешма тарафыннан бирелгән мәгълүматның дөрес булмау фактын билгеләү;

коммерциягә карамаган оешма заявканы Министрлык тарафыннан субсидия турында мәгълүмат Бердәм порталда урнаштырылган көненнән соң килә торган 10 эш көне узгач бирү.

4.4. Коммерциягә карамаган оешмага субсидия бирү турында карар кабул ителгән очракта, Министрлык, әлеге карар кабул ителгән көннән алып 10 эш көненнән дә соңга калмыйча, коммерциягә карамаган оешма белән Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип форма нигезендә субсидия бирү турында килешү (алга таба – Килешү) төзи.

Килешү «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итъ буенча дәүләт берләштерелгән мәгълүмат системасында (алга таба – «Электрон бюджет» системасы) электрон документ рәвешендә төзелә һәм һәр як исеменнән эш итәргә хокуклы затларның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән кул куела.

Килешүдә түбәндәгеләр карала:

субсидиянең күләме, аның максатчан билгеләнеше, аны күчерү сроклары һәм тәртибе;

коммерциягә карамаган оешма тарафыннан субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында хисап, финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап һәм өстәмә хисаплар (кирәк булганда) бирү тәртибе һәм сроклары;

коммерциягә карамаган оешманың, коммерциягә карамаган оешма белән (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешмаларыннан тыш) төзелгән шартнамәләр (килешүләр) нигезендә акча алучы затларның үзләренә карата Министрлык тарафыннан субсидия бирү тәртибе һәм шартлары (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә) үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыруга, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^{1}$ һәм $269^{2}$ статьялары нигезендә тикшерүгә ризалыгы;

субсидияне кире кайтару тәртибе һәм сроклары;

әлеге Тәртипнең 1.3 пунктында күрсәтелгән, Килешүдә билгеләнгән күләмдә субсидия бирү мөмкин булмавына китерә торган, Министрлыкка моңа кадәр җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитларын киметкән очракта, Килешүнең яңа шартларын килештерү турында яки яңа шартлар буенча Килешүгә ирешә алмаганда Килешүне өзү хакында шарт;

Коммерциягә карамаган оешма, шулай ук коммерциягә карамаган оешма белән төзелгән шартнамәләр (килешүләр) нигезендә акча алучы башка юридик затлар тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган акча исәбеннән чит ил валютасы (югары технологияле импорт җиһазын, чимал һәм комплектлау әйберләрен сатып алганда (кайтартканда) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән тыш) сатып алуны тыю турында шарт;

субсидия бирү тәмамлануның төгәл датасы һәм аның нәтиҗәләре күрсәткечләре;

4.5. Кирәк булуга карап, Министрлык һәм коммерциягә карамаган оешма Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган бертип форма буенча Килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән Килешүне өзү турында өстәмә килешү төзи.

4.6. Коммерциягә карамаган оешма кушылу, кушу яисә үзгәртеп оештыру рәвешендә үзгәртеп оештырылганда, Килешүгә йөкләмәдә зат алышыну өлешендә Килешүгә өстәмә килешү төзү юлы белән үзгәреш кертелә, Килешүдә хокук варисы булып торган юридик зат күрсәтелә.

Коммерциягә карамаган оешманы бүлү, аерып бирү рәвешендә үзгәртеп оештырганда, шулай ук Коммерциягә карамаган оешма бетерелгәндә Килешү, берьяклы тәртиптә килешүне өзү турында хәбәрнамә булдырып һәм, Коммерциягә карамаган оешма тарафыннан үтәлмәгән, финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган йөкләмәләр һәм субсидиянең файдаланылмый калган өлешен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару турында мәгълүматны чагылдырып, Килешү буенча йөкләмәләрне үтәү турында акт төзеп өзелә.

## V. Субсидия бирү тәртибе

5.1. Министрлык Килешү төзелгән көннән эш көннәрендә исәпләнелә торган 10 көн эчендә коммерциягә карамаган оешманың Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яисә кредит оешмаларында ачылган исәп-хисап счетына яки корреспондент счетына субсидия күчерә.

Коммерциягә карамаган оешма акча керү һәм тотылу буенча аерым бухгалтерлык исәбен алып бара.

Коммерциягә карамаган оешма, шулай ук коммерциягә карамаган оешма белән төзелгән шартнамәләр (килешүләр) нигезендә акчалар алучы башка юридик затлар тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган чит ил валютасы акчалары исәбеннән, югары технологияле импорт җиһазларын, чималны һәм комплектлаучы әйберләрне сатып алганда (китергәндә) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән тыш, акчалар алуны тыю.

Коммерциягә карамаган оешма, коммерциягә карамаган оешма белән (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешмаларыннан тыш) төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затлар үзләренә карата Вәкаләтле орган тарафыннан субсидия бирү тәртибе һәм шартлары (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә) үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыруга, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан оешманың субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәвен Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерүгә ризалык бирә.

5.2. Финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнар юнәлешләренә түбәндәгеләр керә:

а) фән казанышларына нигезләнгән җитештерүләрне үстерүгә һәм яңа прогрессив технологияләрне кертүгә юнәлдерелгән чаралар үткәрүгә бәйле чыгымнарны гамәлгә ашырганда:

«Ел инновациясе» конкурсында җиңүчеләрне бүләкләү тантанасы атрибутларын сатып алу (дипломнар, дипломнар өчен рамкалар һәм чәчәкләр);

«Ел инновациясе» конкурсында җиңүчеләрнең видеовизиткаларын ясау;

«Ел инновациясе» конкурсы проектларына экспертиза үткәрү хезмәтләре өчен түләү;

б) инновация эшчәнлегенә ярдәм күрсәтү, продукцияләрнең һәм технологияләрнең яңа төрләрен җитештерүне әзерләү һәм үзләштерү өчен юридик затларга максатчан заемнар бирү;

в) Татарстан Республикасының инновация һәм инвестиция потенциалын арттыру максаты белән күргәзмә эшчәнлеге белән бәйле чыгымнарны гамәлгә ашырганда:

Россия венчур форумы (алга таба – форум) үткәрү урынын арендалау;

форумны уздыру өчен синхрон тәрҗемә өчен җиһаз, тавыш, яктылык һәм мультимедиа җиһазы, шулай ук башка инвентарь арендалау;

форумны декорацион-техник бизәү (күргәзмә экспозициясен булдыруны, алып килүне, монтажлауны (демонтажлауны) кертеп), җиһаз арендалау;

транспорт хезмәтләре һәм почта чыгымнары өчен түләү;

форумның эшлекле программасын оештыру һәм Россия Федерациясе субъектларыннан делегатлар (модераторлар, спикерлар, экспертлар, компания вәкилләре) җәлеп итү, проектларны сайлап алу буенча судьялар комиссиясе эшен тәэмин итү хезмәтләре өчен түләү;

форумда катнашучыларны теркәүне оештыру һәм файдалану белән идарә итүнең куркынычсыз системасын тәэмин итү;

форумны оештыруга һәм уздыруга бәйле тарату материалларын, презентацияләрне, полиграфия һәм нәшрият хезмәтләрен, реклама һәм мәгълүмат-аналитика материалларын әзерләү (аналитика хисабын бастырып чыгаруны кертеп) хезмәтләре өчен түләү;

форумга лингвистик яктан ярдәм күрсәтеп тору һәм материалларны чит телләргә тәрҗемә итү;

форумны ачу һәм ябу өчен мәдәни программа (музыкаль-бию номерлары) оештыру;

форумда катнашучыларны тукландыруны оештыру;

форумны оештыру һәм үткәрү өчен гражданлык-хокукый шартнамәләр нигезендә, шул исәптән авторлык шартнамәләре нигезендә җәлеп ителгән белгечләрнең хезмәте өчен түләү;

форумны массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту;

г) коммерциягә карамаган оешманың һәм «Россия технологик үсеш фонды» федераль дәүләт автоном учреждениесенең уртак программалары кысаларында проектларны гамәлгә ашыру өчен юридик затларга максатчан заемнар бирү.

Коммерциягә карамаган оешмага бирелә торган субсидия күләме (С) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$C = P_1 + P_2 + P_3 + ... + Pn,$$

монда $P_1$, $P_2$, $P_3$, ..., Pn – әлеге Тәртипнең 3.1 пунктында күрсәтелгән документлар нигезендә Министрлык тарафыннан билгеләнә торган, әлеге Тәртипнең 5.2 пунктында күрсәтелгән юнәлешләр буенча бирелә торган субсидия исәбеннән финанс белән тәэмин ителергә тиешле чыгымнар. Шул ук вакытта субсидия күләме әлеге Тәртипнең 1.3 пунктында күрсәтелгән бюджет ассигнованиеләренең иң чик күләменнән арта алмый.

5.4. Субсидия бирү нәтиҗәләре:

үткәрелгән «Ел инновациясе» конкурслары саны;

инновация эшчәнлегенә ярдәм күрсәтү, продукцияләрнең һәм технологияләрнең яңа төрләрен җитештерүне әзерләү һәм үзләштерү өчен юридик затларга бирелгән максатчан заемнар саны һәм күләме;

форум кысаларында оештырылган күргәзмәләр саны;

коммерциягә карамаган оешманың һәм «Россия технологик үсеш фонды» федераль дәүләт автоном учреждениесенең уртак программалары кысаларында проектларны гамәлгә ашыру өчен юридик затларга бирелгән максатчан заемнар күләме.

Субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткече Килешүдә билгеләнә.

Әлеге пунктта күрсәтелгән нәтиҗәләргә ирешү срогы – 2026 елның 31 декабреннән дә соңга калмыйча.

5.5. Коммерциягә карамаган оешма Министрлыкка «Электрон бюджет» системасыннан түбәндәгеләрне тапшыра:

хисап кварталыннан соң килә торган бишенче эш көненнән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән Килешүнең бертип формасында билгеләнгән форма буенча субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында хисап; IV квартал өчен хисап хисап елыннан соң килә торган елның 25 гыйнварына кадәр бирелә;

хисап кварталыннан соң килә торган бишенче эш көненнән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән Килешүнең бертип формасында билгеләнгән форма буенча финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап; IV квартал өчен хисап хисап елыннан соң килә торган елның 25 гыйнварына кадәр бирелә;

Килешүдә каралган сроклар эчендә һәм формалар буенча өстәмә хисаплылык.

5.6. Министрлык әлеге хисаплар «Электрон бюджет» системасында бирелгән көннән алып 20 эш көненнән артмаган срок эчендә әлеге Тәртипнең 5.5 пунктында күрсәтелгән хисапларны тикшерә.

Министрлык коммерциягә карамаган оешманың субсидия бирү шартларын һәм тәртибен (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә) үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыра.

Дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрүне гамәлгә ашыра.

5.7. Субсидия коммерциягә карамаган оешма тарафыннан Министрлыкның тиешле таләбе алынган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджетына түбәндәге очракларда кире кайтарылырга тиеш:

коммерциягә карамаган оешма тарафыннан субсидия биргәндә билгеләнгән шартлар бозылган очракта, шул исәптән Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр фактлары буенча да – тулы күләмдә;

коммерциягә карамаган оешма тарафыннан субсидия алу өчен дөрес булмаган (тулы булмаган) белешмәләр һәм документлар тапшырылган очракта – тулы күләмдә;

финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап, субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткечләренә ирешү турында хисап, өстәмә хисаплылык (Килешүдә мондый билгеләнгәндә) тапшырылмаган очракта – тулы күләмдә;

коммерциягә карамаган оешма тарафыннан субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткеченә ирешелмәгән очракта – Килешүдә тиешле нәтиҗәгә ирешүгә каралган акча күләмендә;

субсидия акчасы максатчан файдаланылмаганда – максатчан билгеләнеше буенча файдаланылмаган субсидия күләмендә.

5.8. 2025 елда субсидиянең файдаланылмый калган өлеше, 2026 елның 1 мартыннан да соңга калмыйча, Татарстан Республикасы бюджеты керменә кире кайтарылырга тиеш (Министрлык тарафыннан Килешүдә билгеләнгән тәртиптә әлеге акчага ихтыяҗ булу турында карар кабул ителгән очраклардан тыш).

2025 елда файдаланылмаган акчаны әлеге Тәртипнең 1.2 пунктында күрсәтелгән максатларга җибәрүгә ихтыяҗ булган очракта, коммерциягә карамаган оешма, 2026 елның 15 февраленнән дә соңга калмыйча, Министрлыкка әлеге акчага ихтыяҗны нигезләп, мәгълүмат бирә.

Министрлык, коммерциягә карамаган оешмадан әлеге пунктның икенче абзацында күрсәтелгән мәгълүматны алган көннән 10 календарь көннән дә соңга калмыйча, 2026 елда субсидиянең 2025 елда файдаланылмый калган өлешен җибәрүгә ихтыяҗ булу яки булмау турында карар кабул итә.

Министрлык тарафыннан 2026 елда субсидиянең 2025 елда файдаланылмый калган өлешен җибәрүгә ихтыяҗ булу турында карар кабул ителгән очракта, Министрлык һәм коммерциягә карамаган оешма арасында мондый карар кабул ителгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә Килешүгә өстәмә килешү төзелә. Килешүгә өстәмә килешү «Электрон бюджет» системасында электрон документ формасында төзелә һәм һәр як исеменнән эш итәргә хокуклы затларның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана.

5.9. Коммерциягә карамаган оешма тарафыннан әлеге Тәртипнең 5.7 һәм 5.8 пунктларында күрсәтелгән субсидияне кире кайтару сроклары бозылганда, Министрлык субсидияне кире кайтару срогы чыккан көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә әлеге акчаны законнар белән билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетына түләтү буенча чаралар күрә.

5.10. Килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләренең күрсәткечләренә ирешүне һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чара тәмамлану фактын чагылдыра торган вакыйгаларны (контроль нокта) мониторинглау Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән субсидияләр бирү нәтиҗәләренә ирешүне мониторинглау тәртибе нигезендә билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча үткәрелә.

5.11. Субсидияне нәтиҗәле файдалануны контрольдә тоту Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

---

2025 елда устав эшчәнлеген гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен «Татарстан Республикасының Инвестиция-венчур фонды» коммерциягә карамаган оешмасына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә кушымта

Форма

Устав эшчәнлеген гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен «Татарстан Республикасының Инвестиция-венчур фонды» коммерциягә карамаган оешмасына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирүгә гариза

Устав эшчәнлеген гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен «Татарстан Республикасының Инвестиция-венчур фонды» коммерциягә карамаган оешмасына (алга таба – коммерциягә карамаган оешма) Татарстан Республикасы бюджетыннан ____________________________________ сум күләмендә субсидия бирүегезне сорыйм:

1. Фән казанышларына нигезләнгән җитештерүләрне үстерүгә һәм яңа прогрессив технологияләрне кулланышка кертүгә юнәлдерелгән чаралар үткәрү өчен _________________ сум.

2. Инновация эшчәнлегенә ярдәм күрсәтү, продукцияләрнең һәм технологияләрнең яңа төрләрен җитештерүне әзерләү һәм үзләштерү өчен юридик затларга максатчан заемнар бирү өчен ______________________ сум.

3. Татарстан Республикасының инновация һәм инвестиция потенциалын арттыру максаты белән күргәзмә эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен _________________ сум.

4. коммерциягә карамаган оешманың һәм «Россия технологик үсеш фонды» федераль дәүләт автоном учреждениесенең уртак программалары кысаларында проектларны гамәлгә ашыру өчен юридик затларга максатчан заемнар бирү өчен _____________________________ сум.

Салым түләүченең идентификацияләү номеры (ИНН) ______________________.

Исәпкә кую сәбәбе коды (КПП) ________________________________________________.

Исәп-хисап счеты ____________________________________________________.

Банк идентификация коды (БИК) ____________________________________________.

Корреспондент счеты: _________________________________________________.

Икътисадый эшчәнлек төрләренең бөтенроссия классификаторы буенча эшчәнлек төре коды (ОКВЭД 2) ____________________________________.

Коммерциягә карамаган
оешманың җитәкчесе

| | | |
|---|---|---|
| | _______________ | ______________________________________ |
| | (имза) | (Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда)) |

Коммерциягә карамаган
оешманың баш бухгалтеры

| | | |
|---|---|---|
| | _______________ | ______________________________________ |
| | (имза) | (Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда)) |